**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

**21 ноябрь, 2023 ел** — **№ 341**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы беренче өлешенең 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 33 статьялары, Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча 2023 елның 15 сентябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсе, Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча 06-07.10.2023 гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2023 елның 07 июнендәге 299 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләрне кушымта нигезендә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Федераль дәүләт территориаль планлаштыру мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы — Р.Ф. Хисаметдинов

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турындагы материаллары белән территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru) УИН 9262242702020304202308041 буенча танышырга мөмкин.